ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 12 2021 г. № 367

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 198 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Түбән Кама шәһәре Уставының 51 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2015 елның 1 декабрендәге 480 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 198 номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.5.2 пунктның «д» пунктчасына «(челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш)» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкче урынбасары М.А.Санков

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881